Универсаль уку гамәлләре составында белем бирүнең төп максатларына ярашлы 4 блок аерып күрсәтелә:

1. Шәхескә бәйле гамәлләр
2. Юнәлеш алуга караган гамәлләр
3. Танып белү гамәлләре
4. Коммуникатив гамәлләр

**Шәхескә караган универсаль гамәлләр** укучыга әхлак нормаларын белергә, эш-кыланышларны һәм вакыйгаларны кабул ителгән тәртип нормалары белән чагыштырырга, тәртибеңә бәя бирергә өйрәтәләр. Монда 3 төрле гамәл аерып күрсәтелә: 1) шәхси, һөнәри, тормышта үзбилгеләнү; 2) мәгънә барлыкка китерү: укуның нәтиҗәсе белән этәргече арасында мөнәсәбәт урнаштыру; 3) әхлак, этика нормалары кысаларында үз урыныңны билгеләү, юнәлеш ала белү, үзләштерелгәнгә бәя бирү.

**Юнәлеш алуга (регулятив) караган гамәлләр** балаларга үзләренең уку эшчәнлеген оештыру мөмкинлеге бирә. Мондый гамәлләргә түбәндәгеләр керә:

- *максат кую* – үзләштерелгән белән таныш булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын кую;
- *планлаштыру* – азаккы нәтиҗәне күз алдында тортып, ике арадагы максатларның эзлеклелеген билгеләү, план төзү, эш тәртибен билгеләү;
- *прогноз кую* – көтелгән нәтиҗәне сиземләү;
- *тикшерү* – бирелгән үрнәктән тайпылыш яки аермалык булу-булмавын ачыклау максатыннан эш алымын һәм аның нәтиҗәсен бирелгән үрнәк белән чагыштыру;
- *коррекция* – башкарылган эш, аның нәтиҗәсе үрнәк белән туры килмәгәндә, планга өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертү;
- *бәяләү* – үзләштерелгән һәм үзләштереләсе белемнәрне аера белү, үзләштерелгәннең сыйфатын һәм белү дәрәҗәсен аңлау;
- *үзрегуляция* – көч һәм энергияне туплау, ихтыяр көче кую (дәлилләр бәрелеше булган очракта кирәклесен сайлау), каршылыкларны җиңеп чыгу сәләтенә ия булу.

**Танып белүнең универсаль гамәлләре** гомумуку, логик, проблема кую һәм аны чишү гамәлләрен берләштерә.

***Гомумуку универсаль гамәлләре:***

- танып белү максатын мөстәкыйль рәвештә аерып алу һәм әйтеп бирү;
- кирәкле информацияне эзләп табу, компьютер чараларын куллану;
- белемнәрне структуралау, ягъни тәртипкә салу;
- уй-фикерне сөйләмә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештыру;
- бурычларны үтәүнең нәтиҗәле ысулларын сайлау;

- рефлексия – эш-хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын, эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- текст укуның максатын аңлап һәм уку төрен шул максаттан чыгып сайлау нәтиҗәсендә аңлап укуга ирешү;

Танып белүнең универсаль гамәлләре арасында аерым бер төркем – тамга-символик гамәлләр бар:

- модельләштерү
- әзер модельне үзгәртү.

***Логик универсаль уку гамәлләре:***

- анализ – төп һәм мөһим булмаган билгеләрен аерып алу өчен, объектны тикшерү;
- синтез – аерым кисәкләрдән бер бөтен төзү, кирәк булганда, җитмәгән компонентлар  өстәү;
- объектларны чагыштыру, төркемләү өчен нигез һәм критерийлар сайлый белү;
- төшенчәгә китереп җиткерү, нәтиҗә чыгару;
- сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләрне ачыклау;
- фикер йөртүнең логик чылбырын тезү;
- исбатлау;
- гипотеза әйтү һәм аны дәлилләү.

***Проблема кую һәм аны чишү:***

- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- иҗатка һәм эзләнүгә корылган проблемаларның чишелеш алымнарын мөстәкыйль табу.

**Коммуникатив гамәлләргә** түбәндәгеләр керә:

- укытучы һәм сыйныфташлар белән  хезмәттәшлекне планлаштыру;
- сораулар кую – информация эзләү, туплауда хезмәттәшлек;
- конфликтларны чишү;
- әңгәмәдәшнең тәртибенә җитәкчелек итү;
- үз фикереңне тулы һәм төгә итеп әйтә белү.